| ЛЕНИНОГОРСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» | | «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ЛЕНИНОГОРСК РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | | **КАРАР** |

2018 елның 13 декабре №79

Лениногорск муниципаль районы Советының 2013 елның 19 декабрендәге 94 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру тәртибе һәм мәгълүмат урнаштыру чаралары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Лениногорск муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмат урнаштыру чараларын урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салу өлкәсендә бердәм сәясәт булдыру, реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмат урнаштыру чараларын урнаштыруга рөхсәт бирү, аларны техник урнаштыруга, эксплуатацияләүгә һәм демонтажлауга таләпләрне билгеләү вәкаләтләрен тормышка ашыру максатларында,"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ федераль законнарга таянып, "Реклама турында" 13.03.2006 ел, № 38-ФЗ, "Реклама турында "13.06.2006 елдагы Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында"30.11.2013 ел, № 939 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы "Лениногорск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы белән Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Лениногорск муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмат урнаштыру чараларын урнаштыру тәртибе турында» 2013 елның 19 декабрендәге 94 номерлы Лениногорск муниципаль районы Советы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмат урнаштыру чараларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

7.11.1 пунктының 1 пунктчасында «язма рәвештә» сүзләреннән соң «яисә электрон документ рәвешендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын һәм (яисә) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталларын файдаланып» сүзләрен өстәргә.

2. «Лениногорские вести» район газетасында әлеге карарны бастырып чыгарырга һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, салымнар һәм финанс буенча даими комиссиягә, "Лениногорск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Лениногорск муниципаль районы башлыгы,
муниципаль район Советы рәисе Р.Г.Хөсәенов